# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Оешмалар мөлкәтенә салым турында”**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Йөк автотранспорты чараларын җитештерүчеләрнең мөлкәтенә салым ставкасы 0,5 процент күләмендә билгеләнә.”;

2) 5 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) 2014 елның 1 гыйнварыннан Әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 8, 16 пунктлары һәм 2 өлешенең 3, 4, 7 пунктлары;”;

б) 6 пунктта “2 өлешенең 2–5, 7, 8 пунктлары” сүзләрен “2 өлешенең 2, 5, 8 пунктлары” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 8 октябре
№ 73-ТРЗ